РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«11» март 2021 г. г. Альметьевск №34

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга пенсиягә чыгу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе һәм түләү күләмнәренең торышы турында» 2015 елның 10 декабрендәге 37 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 04 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 13 ноябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы уставы нигезендә, бюджет акчаларыннан файдалану нәтиҗәлелеге принцибын үтәүне һәм республика законнары нормаларына туры килүне тәэмин итү максатларында

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга пенсиягә чыгу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе һәм түләү күләмнәренең торышы турында» 2015 елның 10 декабрендәге 37 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2016 елның 29 апрелендәге 72 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затка, муниципаль вазыйфадан пенсиягә чыгу уңаеннан эштән киткәндә, үз эченә ун тапкыр айлык акчалата хезмәт хакы күләмендә бер мәртәбә акчалата бүләкләү түләнә: муниципаль вазыйфада стаж, дәүләт һәм муниципаль хезмәт стажы тулаем алганда

Заказ № 2625

10 елдан артык булганда, айлык акчалата бүләкләү һәм айлык акчалата кызыксындыру бүләге.»;

1.2. 8 пунктта түбәндәге эчтәлекле 8.1 пунктчасы өстәргә:

«8.1. Пенсиягә чыгу уңаеннан бер мәртәбә акчалата түләү Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль вазыйфасын биләүче затның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булмаганда башкарыла. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу уңаеннан бер мәртәбә түләнә торган акчалата бүләкләүне түләү өчен мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көн эчендә җайга салганда, тиешле еллар эшләгән ечен пенсиягә чыгу сәбәпле бер мәртәбә түләнә торган акчалата түләүне түләү мондый түләү ечен мерәҗәгать иткән көннән алып башкарыла.».

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны районның законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (Парфилова Н.В.) йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы — Т.Д. Нагуманов